ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 г. с. Шеланга №1

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның $43^1$ статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы башлыгы белән төзелгән 2016 елның 12 гыйнварындагы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү эше барышында Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентына таянырга һәм алар турында белешмәләрне

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга киңәш итәргә;

2. Җирлек Советының, җирлек башлыгының һәм җирлек башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын, шулай ук регистрга кертелергә тиешле алар турында белешмәләрне район Советына җибәрүе өчен җаваплы итеп җирлек башкарма комитеты җитәкчесен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы

В.В.Майоров